01 ноябрь 2013 Казан ш. 5-25/тэ №лы

***«Казан силикат стена материаллары заводы» ҖЧҖ кулланучыларга тәэмин иткән җылылык энергиясенә тарифларның билгеләнүе турында***

«Җылылк белән тәэмин итү турында» 27 июль 2010 190-ФЗ №лы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә электр һәм җылылык энергияга кагылышлы бәя билгеләнүе турында» 26 февраль 2004 109№лы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Ваклап сату (кулланучы) базарына электр (җылылык) энергиясенә көйләүле бәяләрне (тарифлар) исәп-хисаплау буенча Методик күрсәтмәләренең раслануы турында» 05 август 2004 20-э/2 №лы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 468 №лы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты БОЕРА:

1. Әлеге карарның кушымтасы буенча «Казан силикат стена материаллары заводы» ҖЧҖ кулланучыларга тәэмин иткән җылылык энергиясенә тарифларны билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1нче пунктында билгеләнгән тариф карарның гамәлгә кергән көненнән башлап 31 декабрь 2013 елга хәтле гамәлдә булачак.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә нәшер ителү көненнән ун көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 01 ноябрь 2013
5-25/тэ №лы карарының
Кушымтасы

# «Казан силикат стена материаллары заводы» ҖЧҖ кулланучыларга тәэмин иткән җылылык энергиясенә тарифлар

| № п/п | Муниципаль оешманың, җылылык белән тәэмин итүче оешманың исеме, кулланучыларның категорияләре | Җылылк энергиясенә тариф | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су | Басымлы сайланма пар | | | | Үте һәм киметелгән пар |
| | | | 1,2 дән 2,5 кә хәтле кг/см$^2$ | 2,5 тән 7,0 гә хәтле кг/см$^2$ | 7,0 дән 13,0 гә хәтле кг/см$^2$ | 13,0 дән югары кг/см$^2$ | |
| | Казан шәһәре | | | | | | |
| 1 | «Казан силикат стена материаллары заводы» ҖЧҖ | | | | | | |
| 1.1 | Җылылык энергиясенең җитештерелүе һәм тапшырылуы өчен түли торган кулланучылар | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | - | - | - | 1034,10 | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының карарларының алыну
оештыру, тикшерү һәм алып бару бүлеге